**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# КАРАР
**Яңа Кенәр авыл җирлеге**

**«26» ноябрь 2025 ел** **№ 10**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 129 номерлы карарына (2024 елның 10 сентябрендәге 156 нчы номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 29.11.2023 №129 карарына (2024 елның 10 сентябрендәге 156 нчы номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 4. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

4.1. дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган гражданнарны;

4.2. әлеге пунктның 4.1 подпунктында күрсәтелгән физик затларның балаларын.

Салым ташламасы салым салынырга тиешле объектларның түбәндәге төрләренә карата бирелә:

– фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

– торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

– гараж яки машина кую өчен урын.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләмәләр санына карамастан, салым түләүченең сайлавы буенча, гаиләгә туры килгән һәр төрдән бер объекка карата гына бирелә.

Салым ташламасы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин

СОВЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ